ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КУТЛУ-БУКАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422665, с. Кутлу-Букаш,
ул. Советская, дом 32

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КОТЛЫ БӨКӘШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422665, Котлы Бөкәш авылы,
Совет урамы, 32 нче йорт,

Тел.: (84361) 31642, факс: (84361) 31642, e-mail:Kbuk.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 елның 16 ноябре Котлы Бөкәш ав. № 32

# 2017-2035 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Җирлекләрнең, шәһәр округларының социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларына карата таләпләрне раслау турында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 1 октябрендәге 1050 нче номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең Генераль планы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2017-2035 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын расларга.
2. Әлеге карарны җирлекнең “Интернет”челтәрендәге рәсми сайтында һәм ТР Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (игълан итәргә).
3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Котлы Бөкәш авыл җирлеге Башлыгы Г. Г. Нәҗипов

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль**
**районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге**
**Башкарма комитетының**
**2017 елның 16 ноябрендәге**
**32 нче номерлы карары белән**
**расланды**

# 2017-2035 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасы

Программаның паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның аталышы | 2017-2035 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасы |
| Программаны эшләү өчен нигез | -“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон<br>- Котлы Бөкәш авыл җирлегенең Генераль планы<br>- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасы |
| Программаның заказ бирүчесенең исеме, аның урнашу урыны | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге Башкарма комитеты,адрес: 422665, ТР, Балык Бистәсе муниципаль районы, Котлы Бөкәш авылы, Совет урамы, 32 нче йорт |
| Программаны эшләүченең аталышы, аның урнашу урыны | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге Башкарма комитеты,адрес: 422665, ТР, Балык Бистәсе муниципаль районы, Котлы Бөкәш авылы, Совет урамы, 32 нче йорт |
| Программаның максаты | Социаль-көнкүреш ихтыяҗлары нигезендә инфраструктура һәм объектларның социаль системаларын үстерүне тәэмин итү, халыкның яшәү шартларын яхшырту һәм әлеге инфраструктураны үстерүнең төгәл балансланган перспективасын билгеләү. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсешен яхшырту. |
| Программаның бурычлары | - Котлы Бөкәш авыл җирлеге халкының социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин ителеше дәрәҗәсен күтәрү;<br>- Котлы Бөкәш авыл җирлеге халкы тарафыннан социаль инфраструктура объектларын файдалануның иминлеге, сыйфаты һәм нәтиҗәлелеге;<br>- Котлы Бөкәш авыл җирлегенең социаль инфраструктура объектларына булган билгеләнгән ихтыяҗлары нигезендә Котлы Бөкәш авыл җирлеге социаль инфраструктурасының баланслы, перспективалы үсеше;<br>- шәһәр төзелешен проектлаштыру нормативлары нигезендә; мәгариф, сәламәтлек саклау, физик культура һәм гаммәви спорт һәм мәдәният өлкәләрендә җирлек халкының хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителешенең исәп-хисап дәрәҗәсенә ирешү; |

| | |
|---|---|
| | - гамәлдәге социаль инфраструктура эшләвенең нәтиҗәлелеге. |
| Халыкның социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин ителешенең максатчан күрсәткечләре (индикаторлары) | Социаль инфраструктура объектларын төзү күләмнәренең үсеше. |
| Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | Программаны тормышка ашыру срогы – 2017-2035 еллар.<br>I этап – 2017 елдан 2021 елга кадәр<br>II этап – 2022 елдан 2035 елга кадәр |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары –Татарстан Республикасы бюджеты |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре. | Котлы Бөкәш авыл җирлеге халкының перспективадагы санын исәпләү нигезендә социаль инфраструктурасы объектлары белән тәэмин ителеше. Социаль инфраструктура хезмәтләренә халыкның ихтыяҗын канәгатьләндерү. |

Халыкның тормыш (тереклек) эшчәнлеге социаль инфраструктура булдыру һәм үстерү белән тәэмин ителә – эшчәнлекләре кешенең мәгарифкә, медицина хезмәтенә ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә, ял вакытын оештыруга, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә юнәлтелгән оешмалар һәм учреждениеләр җыелмасы белән. Халыкның тормыш дәрәҗәсен яхшырту - социаль сәясәтнең өстенлекле бурычы. Бу бурычны хәл итүдә төп юнәлешләрнең берсе- Балык Бистәсе муниципаль районының социаль-икътисади үсешен тәэмин итә торган үсеш алган социаль инфраструктура булу. “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Законны гамәлгә ашыру зарурлыгы муниципаль дәрәҗәдә генә түгел, аерым авыл җирлекләре дәрәҗәсендә дә нәтиҗәле үсеш стратегиясен эшләү ихтыяҗын актуальләштерде. Авыл җирлеген үстерүнең стратегик планы аның территориясендә яшәүче халыкның һәм аның территориясендә барган процессларның ихтыяҗларына җавап бирә. Котлы Бөкәш авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасында (алга таба – Программа) җирлекнең стратегик максатлары, ресурслары, потенциалы һәм уртача сроклы перспективага социаль үсешенең төп юнәлешләре турында төгәл күзаллаулар тупланган. Моннан тыш Программа авыл җирлеген социаль үстерүнең стратегик максатларына ирешүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру өчен ресурслар, башкаручылар һәм сроклар буенча бәйле җыелманы үз эченә ала. Җирлекне үстерү максатлары һәм программа чаралары, шулай ук аларны тормышка ашыру өчен программада билгеләнгән кирәкле ресурслар, килеп туган хәлгә, эчке һәм тышкы шартларның үзгәрүенә карап, ел саен төзәтмәләр кертелә һәм тулыландырыла ала. Әлеге программаны эшләү Котлы Бөкәш авыл җирлегенең тотрыклы үсешенең социаль әһәмияте буенча өстенлекле стратегик линияләрен билгеләү зарурлыгына бәйле – потенциалга ия булган территорияләр, географик, демографик, икътисадый, социаль-мәдәни потенциалга, җирлек социумы өчен перспективалы һәм актуаль булган территорияләр. Программа икътисадны тотрыклыландыруга һәм үстерүгә, халыкның мәшгульлеге дәрәҗәсен күтәрүгә, социаль проблемаларны хәл итүгә ярдәм итә торган чаралар комплексын гамәлгә ашыруга юнәлтелгән.

Программа гамәлдәге законнар таләпләре нигезендә эшләнгән. Программа Балык Бистәсе муниципаль районының Котлы Бөкәш авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын үстерү өчен сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният объектларын капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләү юлы белән шартлар тудырырга тиеш.

## 1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бүкәш авыл җирлеге социаль инфраструктурасының гамәлдәге торышына (хәленә) сыйфатлама

### 1.1 Җирлекнең социаль-икътисадый хәле тасвирламасы

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Котлы Бөкәш авыл җирлеге түбәндәге торак пунктларны үз эченә ала: Котлы Бөкәш, Мәмле Казак Чаллысы, Сатлыган, Тәбәрде Чаллысы авыллары.

Административ үзәге – Котлы Бөкәш авылы.

Котлы Бөкәш авыл җирлегендә халык саны: 1984 кеше.

Котлы Бөкәш авыл җирлегенең административ үзәгеннән район үзәгенә кадәр ераклык 40 км, Республика үзәгенә кадәр (Казан ш.) – 125 км.

Муниципаль берәмлек җирләренең гомуми мәйданы – 488,3га.

### 1.2. Гамәлдәге социаль инфраструктура объектларының техник-икътисадый параметрлары

Авыл җирлегендә түбәндәге учреждениеләр һәм оешмалар урнашкан:

*(Авыл җирлеге территориясендә булган барлык учреждениеләр һәм оешмаларны тасвирларга кирәк)*

1. Белем бирү учреждениеләре: МБМУ- 1,укучылар саны-219;
2. Сәламәтлек саклау учреждениеләре: Котлы Бөкәш авылында табиблык амбулаториясе, ФАП-2 данә, Мәмли Казак Чаллысы, Тәберде Чаллысы авылларында;
3. Мәдәни-ял итү тибындагы учреждениеләр: китапханәләр саны – 2 берәмлек, АМЙ – 2 берәмлек Котлы Бөкәш авылында 350 урынга, Тәберде Чаллысы авылында 50 урынга;
4. Котлы Бөкәш авылында спорт мәйданчыгы -2 берәмлек;
5. Почта элемтәсе бүлекчәсе (Почта) – 1 берәмлек.
6. Кибетләр – 11 данә.

### 1.3. Социаль инфраструктура хезмәтләренә фаразланган ихтыяж

Базар икътисады үсеш алган саен социаль өлкәнең әһәмияте даими рәвештә арта бара. Социаль инфраструктура – эшчәнлеге шәхси ихтыяҗларны канәгатьләндерүгә, тормыш эшчәнлеген һәм халыкның интеллектуаль үсешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән объектлар җыелмасы, ул – мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, туризм һ.б. хезмәтләр күрсәтү рәвешендә социаль уңайлыклар тудыручы милли хуҗалык тармаклары җыелмасы. Социаль өлкә тармаклары иҗтимагый җитештерү үсешендә зур әһәмияткә ия. Алар халыкның тормыш-көнкүрешенә, тормыш сыйфатына турыдан-туры йогынты ясый.

**Мәгариф үсешен фаразлау һәм планлаштыру.**

Социаль өлкә тармаклары арасында мәгариф мөһим урын алып тора. Гомуми белем бирү мәктәбенең уңышлы эшләвенең төп шарты – бу аның матди-техник базасын тиешле хәлдә тоту. Гомуми белем бирү мәктәпләре заманча техник чаралар белән җиһазландырылырга, дәреслекләр һәм күрсәтмә әсбаплар белән тәэмин ителергә тиеш.

| Күрсәткечләр | Үлчәү берәмлеге | Фактта | Фаразланган |
|---|---|---|---|
| 1-6 яшьлек балалар саны | кеше | 50 | 50 |
| Балалар бакчасына йөри | кеше | 47 | 47 |
| Балалар бакчасында төркемнәр саны | данә | 4 | 4 |
| 7-17 яшьлек балалар саны | кеше | 219 | 219 |
| 5 яшьтән 18 яшькә кадәрге балаларга өстәмә белем алу | % | 100 | 100 |

**Сәламәтлек саклау өлкәсен фаразлау һәм планлаштыру.**

Сәламәтлек саклау халыкның сәламәтлеген яхшыртуга, гомер озынлыгын арттыруга ярдәм итә. Сәламәтлек саклау системасын киңәйтү, заманча медицина җиһазларын куллану нәтиҗәсендә медицина хезмәте күрсәтү сыйфатын яхшыртуга, авыруларны киметүгә ирешелә. Сәламәтлек саклауның беренче чираттагы бурычлары:

- сәламәтлек саклау учреждениеләрендә медицина ярдәменең билгеләнгән күләмен һәм профилактик хезмәт күрсәтүләрне гарантияләү;
- гамәлдәге учреждениеләрне беренче чиратта реконструкцияләү һәм яңаларын төзү;
- квалификацияле белгечләр белән тәэмин итү.

| Күрсәткечләр | Үлчәү берәмлеге | Фактта | Фаразланган |
|---|---|---|---|
| фельдшер-акушерлык пунктлары | кеше./смена | 18 | 20 |

**Мәдәният һәм спорт учреждениеләре үсешен фаразлау.**

Мәдәният өлкәсендә төп бурычлар булып тора: учреждениеләрнең гамәлдәге челтәрен саклап калу; һөнәри һәм үзешчән коллективларның иҗади потенциалын арттыру; халыкның нәфис сәнгатен, халык һөнәрчелеген һәм традицион мәдәниятне саклап калу һәм үстерү; тармакның экспозиция-күргәзмә эшләрен һәм фәнни-агарту базасын киңәйтү, мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре күрсәтә торган хезмәтләрнең дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрү һәм аларның халык өчен мөмкин булуын тәэмин итү.

| Күрсәткечләр | Үлчәү берәмлеге | Фактта | Фаразланган |
|---|---|---|---|
| тәэмин ителеш: | | | |
| һәркем файдалана ала торган китапханәләр | учреждение | 2 | 2 |
| мәдәни-ял итү тибындагы учреждениеләр | учреждение | 2 | 2 |
| Социаль-мәдәни чараларда катнашучылар саны | катнашучылар саны | 400 | 400 |
| Спорт корылмалары саны | данә | 2 | 2 |
| Физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче гражданнар өлеше | % | 30 | 50 |

**1.4. Җирлекнең социаль инфраструктурасын үстерү һәм эшләве өчен кирәкле норматив-хокукый базаны бәяләү.**

Муниципаль берәмлекнең социаль инфраструктурасы – катлаулы комплекс, ул кешеләр тормышының төрле төрләре өчен төзекләндерелгән хуҗалык территориясен, социаль хезмәтләр күрсәтү һәм сервис эшчәнлеге системалары составындагы хезмәт күрсәтүләр өлкәсен үз эченә ала, шулай ук халыкның имин яшәвенә юнәлдерелгән социаль инфраструктураның эшләве һәм үсеше белән идарә итүнең институциональ яктан тәэмин ителгән системасы ул.

Социаль инфраструктураны формалаштыру һәм үстерү шәһәр төзелеше кагыйдәләренә, территорияне төзекләндерү буенча теге яисә бу карарларны җирле үзидарә органы (алга таба –

ҖҮИО) кабул иткәндә гавами тыңлаулар барышында гражданнарның активлыгына бәйле. Социаль инфраструктура элементларын үстерү белән идарә итүнең муниципаль берәмлекнең теге яисә бу тибындагы ҖҮИО вәкаләтләренә ярашлы рәвештә өстенлекле юнәлешләре социаль өлкә һәм сервис эшчәнлеге объектларын, урам-юл челтәрен һәм кабул ителә торган идарә карарларын объективлаштыруны мәгълүмати тәэмин итү системасын үстерү булып тора.

ҖҮИО социаль тармакларның вәкаләтле оешмаларыннан, шулай ук сервис эшчәнлеге белән шөгыльләнүче эшкуарлардан чыккан социаль инфраструктураны үстерү буенча инициативаларны хупларга тиеш, шул исәптән, төрле механизмнарны да кертеп, муниципаль заказны формалаштыру юлы белән: максатчан программалар, төзелеш өчен җир бүлеп бирү, торак урыннарны арендалау буенча ташламалар һ. б. Муниципаль берәмлекләрнең социаль инфраструктурасын үстерү өлкәсендә хосусый-дәүләт партнерлыгы әлегә бизнес һәм җәмгыять ягыннан актив ярдәм алмады.

## 2. Социаль инфраструктура объектларын проектлаштыру, төзү һәм реконструкцияләү буенча чаралар (инвестицион проектлар) исемлеге (аларны гамәлгә ашыру башка нигезләр буенча бюджеттан тыш чыганаклар хисабына каралган).

Халыкның мәдәни һәм көнкүреш хезмәте күрсәтүгә, хәйрия фондларына һәм иганәчелеккә юнәлдерелә торган шәхси акчалар, профсоюз һәм иҗтимагый оешмалар акчалары инвестицияләрнең мөһим чыганагы булырга мөмкин.

## 3. Финанслау күләмен һәм чыганакларын бәяләү

Каралган программа чараларын финанслау Балык Бистәсе муниципаль районына республика бюджетыннан гомуми финанслау суммасыннан 100% күләмендә субсидияләр хисабына планлаштырыла.

Программа чараларын республика бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашыру чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет турындагы законда тиешле тармаклар буенча каралган ассигнованиеләр кысаларында гамәлгә ашырыла.

**Таблица №1 Программаның максатчан күрсәткечләре**

| № | Программаның максатчан күрсәткечләре аталышы | Үлчәү берәмлеге | Программаны тормышка ашыра башлауга база күрсәткече | Максатчан күрсәткечнең еллап кыйммәте | | | | | 2022-2035 еллар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | |
| 1 | Котлы Бөкәш авылында мәктәпкә һәм балалар бакчасына капиталь ремонт | объект | | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 1 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 | Тәберде Чаллысы авылы мәдәният йортына капиталь ремонт | объект | | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 1 |
| 3 | Тәберде Чаллысы авылы ФАП на капиталь ремонт | | | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 1 |
| 4 | 350 урынлы Котлы Бөкәш авылы клубына капиталь ремонт | | | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 1 |
| 5 | Котлы Бөкәш авылында универсаль спорт мәйданчыгы төзелеше | | | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 1 |

**ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ**

Таблица - Программа чаралары (финанс ихтыяҗларын бәяләү һәм финанслау чыганаклары)

| Чараның аталышы | Финанслау чыганаклары | Башкару бәясе, мең сумнарда | Чараларны тормышка ашыруга финанс ихтыяҗлары, мең сумнарда | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | 2022-2035 |
| Котлы Бөкәш авылында мәктәпкә һәм балалар бакчасына капиталь ремонт | Берләштерелгән Бюджет | | | | | | | 13650 |
| Тәберде Чаллысы авылы мәдәният йортына капиталь ремонт | Берләштерелгән Бюджет | | | | | | | 1460,0 |
| Котлы Бөкәш авылы клубына капиталь ремонт | Берләштерелгән Бюджет | | | | | | | 4300 |
| Котлы Бөкәш авылында универсаль спорт мәйданчыгы төзелеше | Берләштерелгән Бюджет | | | | | | | 2500 |
| Тәберде Чаллысы авылы ФАП на капиталь ремонт | Берләштерелгән Бюджет | | | | | | | 600,0 |

**4. Программа чараларының нәтиҗәлелеген бәяләү.**

Комплекслы үсеш программасы җирлекнең социаль инфраструктурасын үстерүдә уңай нәтиҗә бирәчәк чаралар комплексын башкаруны күздә тота. Алга киткән социаль инфраструктура булганда, муниципаль берәмлек бизнес алып бару өчен үзенә җәлеп итеп торачак. Бу очракта тәкъдим ителгән программаны тормышка ашыру төп уңай нәтиҗәләрне билгели: бюджет, коммерция, социаль нәтиҗәлелекне.

Коммерция нәтиҗәсе - кече һәм урта бизнесны үстерү, эшлекле инфраструктураны үстерү, эшлекле имиджны арттыру.

Бюджет нәтиҗәсе - предприятиеләрне үстерү бюджет керемнәренең артуына китерәчәк.

Социаль нәтиҗәлелек - яңа эш урыннары булдыру, торак фондын арттыру, коммуналь хезмәтләрнең сыйфатын күтәрү.

## **5. Җирлекнең социаль инфраструктурасы объектларын проектлаштыру, төзү һәм реконструкцияләү өлкәсендә эшчәнлекне норматив-хокукый һәм мәгълүмати тәэмин итүне камилләштерү буенча тәкъдимнәр.**

2017-2035 елларга Котлы Бөкәш авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасы югарыда билгеләнгән система билгеләре буенча төркемләнгән һәм булган ресурслардан һәм территория потенциалыннан нәтиҗәле файдалану нигезендә җирлекнең төп социаль-икътисади максатларына ирешүгә юнәлдерелгән конкрет чаралар һәм көтелгән нәтиҗәләр рәвешендә тәкъдим ителә. Авыл җирлеге белән идарә итүгә күчү халыкның иминлеге, икътисадый тотрыклылык һәм куркынычсызлык мәнфәгатьләре аша, конкрет эчтәлекле һәм программа чаралары рәвешендә белдерелә, аерым авылларның да, тулаем муниципаль берәмлекнең дә социаль-икътисади үсешен тәэмин итәргә мөмкинлек бирә.

Авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын үстерү буенча уртача сроклы программаны эшләү һәм кабул итү социаль, финанс, инвестицион, икътисади сәясәт приоритетларын беркетергә, күп еллар эчендә җыелган проблемаларны хәл итү тәртибен һәм срокларын билгеләргә мөмкинлек бирә. Ә авыл җирлеге территориясендә “уен кагыйдәләре” н беркетүче программалар һәм аны тормышка ашыру өчен төзелә торган механизмнар авыл җирлегенең идарәче һәм эшкуарлык кадрларының эшлекле активлыгын арттырырга, аның территориясендә икътисадый һәм хуҗалык эшчәнлеген активлаштыру өчен кирәкле шартлар булдырырга мөмкинлек бирәчәк.